ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына һәм «Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны торак урыннары белән тәэмин итү турында һәм «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү турында» 529-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына һәм «Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны торак урыннары белән тәэмин итү турында һәм «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү турында» 529-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2024 елның 15 феврале
№ 2350-VI ДС

проект

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинеты
тарафыннан кертелә

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына һәм «Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны торак урыннары белән тәэмин итү турында һәм «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү турында**

**1 статья**

«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8 статьясындагы 5 пунктының икенче абзацына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 12 (II өлеш), № 12 (III өлеш); 2005, № 2; 2006, № 2 (I өлеш); 2007, № 11; 2008, № 5 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2010, № 10 (II өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш); 2013, № 1, № 5; 2014, № 4, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 4, № 12 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнары җыентыгы, 2016, № 44 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 38 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш); 2020, № 57 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 20 (I өлеш), № 49 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 90 (I өлеш), № 96 (I өлеш); 2023, № 92 (I өлеш), № 95 (I өлеш), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«Ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар категориясенә кергән затлар, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган, 23 яшькә җиткән затлар Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә милеккә төзекләндерелгән торак сатып алуга яки заемчының йөкләмәләре ипотека белән тәэмин ителү шартнамәсе буенча кредитны (заемны) тулысынча түләү өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчалары хисабына бер тапкыр түләү алуга хокуклы.».

**2 статья**

«Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны торак урыннары белән тәэмин итү турында һәм «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8

статьясына үзгәреш кертү хакында» 2013 елның 12 гыйнварындагы 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 1, № 10; 2014, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 4; Татарстан Республикасы законнары җыентыгы, 2018, № 1 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш); 2023, № 56 (I өлеш), № 92 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) исемне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**«Ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның, алар арасыннан булган затларның торак урынга хокукларын гамәлгә ашыру турында»**

2) преамбулада «ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга, ятим балалар арасыннан һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларга (алга таба шулай ук – ятим балалар, ятим бала) махсуслаштырылган торак фондыннан махсуслаштырылган торак урыннарын яллау шартнамәләре буенча торак урыннары бирү тәртибен билгели» сүзләрен «ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны, ятим балалар арасыннан һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларны (алга таба шулай ук – ятим балалар, ятим бала) торак урынга хокукын гамәлгә ашыру белән бәйле мөнәсәбәтләрне җайга сала» сүзләренә алмаштырырга;

3) 2 статьяның 4 өлешендә «$3^1$ өлешендә» сүзләрен «$3^1$ пунктында» сүзләренә алмаштырырга;

4) $2^1$ статьяның 1 өлешендә «4 өлешендә» сүзләрен «4 пунктында» сүзләренә алмаштырырга;

5) түбәндәге эчтәлектәге $3^1$ статьяны өстәргә:

«$3^1$ статья. **Төзекләндерелгән торак урынын милеккә сатып алуга яки заемщикның бурычлары ипотека белән тәэмин ителгән килешү буенча кредитны (заемны) тулысынча түләү өчен түләү рәвешендә торак урынга хокукның өстәмә гарантияләре**

1. Федераль законның 8 статьясындагы 9 пунктында күрсәтелгән, әлеге Законның 2 статьясы нигезендә исемлеккә кертелгән затлар, Федераль законның $8^1$ статьясындагы 2 пунктында күрсәтелгән шартлар җыелмасы булганда, Татарстан Республикасы бюджеты акчалары хисабына төзекләндерелгән торак урынын милеккә сатып алуга яки заемщикның бурычлары ипотека белән тәэмин ителгән килешү буенча торак сатып алуга кредитны (заемны) тулысынча түләү өчен бер тапкыр бирелә торган түләүгә (алга таба – түләү) хокуклылар.

2. Вәкаләтле орган торак урыннарын түләү хисабына сатып алуны контрольдә тота, шул исәптән түләүне алучы ала торган торак урынның билгеләнгән санитар һәм техник кагыйдәләргә һәм нормаларга, законнарның башка таләпләренә туры килүе, әлеге торак урынны яшәү өчен яраксыз дип тану һәм (яисә) әлеге торак

урнашкан күпфатирлы йортны авария хәлендәге һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану турында мәгълүматның булу-булмавы турында ведомствоара запрослар җибәрү һәм алу юлы белән.

3. Түләү бирү, шул исәптән түләүне күчерү өчен кирәкле документларны тикшерү, түләүне күчерү һәм түләү хисабына торак урыннарын сатып алуны контрольдә тоту вәкаләтле орган тарафыннан Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртип нигезендә башкарыла.

4. Түләүне бирү яки аны бирүдән баш тарту турында карарны Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртипкә ярашлы рәвештә, Федераль законның $8^1$ статьясының 2 пунктында күрсәтелгән шартлар җыелмасын исәпкә алып, вәкаләтле орган тарафыннан төзелгән комиссия (алга таба – комиссия) кабул итә. Комиссия эшчәнлеге Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләт биргән федераль башкарма хакимият органы тарафыннан расланган нигезләмәгә ярашлы рәвештә башкарыла.

5. Түләү алу хокукы торак урынын сатып алу өчен исемле документ - сертификат белән раслана, аның формасы, аны чыгару һәм гамәлгә ашыру кагыйдәләре Федераль законның $8^1$ статьясының 11 пунктына ярашлы рәвештә раслана.

6. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән затларга сертификат бирү комиссиянең түләү бирү турындагы карары нигезендә вәкаләтле орган тарафыннан башкарыла.»;

6) 5 статьяга түбәндәге эчтәлектәге $5^2$ һәм $5^3$ өлешләрне өстәргә:

«$5^2$. Махсуслаштырылган торак урынын арендалау килешүенең гамәлдә булу вакыты махсуслаштырылган торак урынын арендалау килешүе төзелгән зат инициативасы буенча кыскартылырга мөмкин, әмма ике елдан артыкка түгел, әлеге зат тарафыннан мондый килешүнең гамәлдә булу вакытын кыскарту турында вәкаләтле органга гариза бирелгән көнгә карата Федераль законның 8 статьясындагы $6^2$ пунктында билгеләнгән шартлар җыелмасы булганда.

$5^3$. Махсус торак урынын арендалау килешүенең гамәлдә булу вакытын кыскарту турында гаризага өстәп бирелгән документлар исемлеге, күрсәтелгән гаризаны тапшыру һәм карау тәртибе, мондый килешүнең гамәлдә булу вакытын кыскарту турында карар кабул итү турында яки мондый килешүнең гамәлдә булу вакытын кыскартудан баш тарту турында мәгълүмат җибәрү тәртибе (шул исәптән дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге яисә «Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы аша) Федераль законның 8 статьясының $6^3$ пунктына ярашлы рәвештә раслана.»;

7) $5^1$ статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$5^1$ статья. **«Социаль өлкәдә бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформа» дәүләт мәгълүмат системасында ятим балаларның торак урынга хокукларын гамәлгә ашыру турында мәгълүмат урнаштыру**

1. «Социаль өлкәдә бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформа» дәүләт мәгълүмат системасында түбәндәге мәгълүмат урнаштырылырга тиеш:

1) әлеге Закон нигезендә ятим балаларга махсуслаштырылган торак фондының махсус торак биналарын арендалау килешүләре буенча торак урыннары бирү турында;

2) түләү бирү турында, шул исәптән сертификатның теркәү номеры, сертификат бирү турында вәкаләтле орган карары, сертификат бирү датасы һәм түләү хисабына сатып алынган торак урынын сатып алу-сату килешүен төзү датасы, түләү күләме, сатып алынган торак урынының адресы, түләү алучыны исемлектән чыгару датасы турында.

2. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән мәгълүматны «Социаль өлкәдә бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформа» дәүләт мәгълүмат системасында урнаштыру һәм алу «Дәүләт социаль ярдәме турында» 1999 елның 17 июлендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законга ярашлы рәвештә башкарыла.».

**3 статья**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. «Ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның, алар арасыннан булган затларның торак урынга хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2013 елның 12 гыйнварындагы 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 5 статьясындагы $5^2$ һәм $5^3$ өлешләрендәге нигезләмәләрнең гамәлдә булуы әлеге Закон үз көченә кергән көнгә кадәр төзелгән махсуслаштырылган торак урыннарны арендалау килешүләренә кагыла.

3. «Ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның, алар арасыннан булган затларның торак урынга хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2013 елның 12 гыйнварындагы 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының $5^1$ статьясындагы 1 өлешнең 2 пунктының «Социаль өлкәдә бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформа» дәүләт мәгълүмат системасын куллану өлешендәге нигезләмәләре 2026 елның 1 гыйнварыннан кулланыла.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына һәм «Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны торак урыннары белән тәэмин итү турында һәм «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы закон проектына**

# АҢЛАТМА

«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына һәм «Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны торак урыннары белән тәэмин итү турында һәм «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы закон проекты «Ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга социаль ярдәм күрсәтү буенча өстәмә гарантияләр турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 4 августындагы 461-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – Федераль закон) кабул ителүгә бәйле рәвештә эшләнде.

Закон проекты 23 яшькә җиткән, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар категориясенә кергән, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар, алар арасыннан булган затлар исемлегенә кертелгән затларга милеккә төзекләндерелгән торак сатып алуга яки заемчының йөкләмәләре ипотека белән тәэмин ителү шартнамәсе буенча кредитны (заемны) тулысынча түләү өчен (алга таба – түләү) Татарстан Республикасы бюджеты акчалары хисабына өстәмә ярдәм чарасын билгели.

Түләүнең минималь күләме Федераль закон нигезендә торак урын мәйданының Татарстан Республикасы буенча уртача базар бәясеннән чыгып исәпләнә, әмма торак урын мәйданының 33 квадрат метрына тапкырланган федераль уртача базар бәясеннән түбән түгел. Шулай итеп, 2024 елның I кварталына түләү күләме 4 393 257 сумнан ким булмаска тиеш (133 129 сум х 33 кв. м).

Бер үк вакытта «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законына аныклаучы үзгәрешләр кертү күздә тотыла.

Моннан тыш, закон проекты белән «Ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга социаль ярдәм күрсәтү буенча өстәмә гарантияләр турында» 1996 елның 21 декабрендәге 159-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясындагы $6^2$ пунктында билгеләнгән шартлар җыелмасы булганда (билгеле бер керем дәрәҗәсе булу, салымнар һәм җыемнар буенча бурычлар булмау, хөкем ителмәү һәм башкалар) мондый килешүне төзелгән зат инициативасы буенча махсуслаштырылган торакны арендалау килешүенең гамәлдә булу вакытын 5 елдан 3 елга кадәр кыскарту мөмкинлеген күздә тоткан үзгәрешләр кертелә.

**«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына һәм «Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны торак урыннары белән тәэмин итү турында һәм «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

# ИСЕМЛЕГЕ

«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына һәм «Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны торак урыннары белән тәэмин итү турында һәм «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү турында»Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарларына үзгәрешләр кертүне таләп итә:

«Махсуслаштырылган торак фондының торак урыннарын махсуслаштырылган торак урыннары наймы шартнамәсе буенча яллаучы булып торган ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларга, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар категориясенә кергән затларга, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган, 23 яшькә җиткән затларга авыр тормыш шартларын җиңүдә ярдәм күрсәтү кирәклеге турында таныклаучы хәлләрне ачыклау тәртибен раслау хакында» 2019 елның 30 апрелендәге 371 номерлы;

«Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны торак урыннары белән тәэмин итү турында һәм «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2013 елның 12 гыйнварындагы 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру чаралары турында» 2013 елның 4 маендагы 312 номерлы.

Шулай ук башкарма хакимиятнең опека һәм попечительлек өлкәсендә республика вәкаләтле органының милеккә төзекләндерелгән торак сатып алуга яки заемчының йөкләмәләре ипотека белән тәэмин ителү шартнамәсе буенча кредитны (заемны) тулысынча түләү өчен акча бирү турында яки аны бирүдән баш тарту турында карар кабул итүче комиссиясен булдыру турында оештыру-идарә актын чыгару таләп ителәчәк.

**«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына һәм «Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны торак урыннары белән тәэмин итү турында һәм «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проектын**

# ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ

Ятим балалар арасыннан булган затларга түләүләр Татарстан Республикасы буенча Татарстан Республикасында 1 кв. м торакның уртача базар бәясен исәпкә алып, 2024 елның I кварталына 4 393 257 сумнан (133 129 сум х 33 кв.м) ким булмаска тиеш.

Бердәм дәүләт социаль тәэмин итү мәгълүмат системасы мәгълүматларына караганда, ятим балалар арасыннан 2024 елның гыйнварына торак биналар белән тәэмин ителмәгән 23 яшьтән өлкәнрәк 386 кеше исәпләнә.

Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 2023 елның 11 декабрендәге «Россия Федерациясе буенча 2024 елның беренче яртыеллыгына торак бинаның гомуми мәйданының бер квадрат метры бәясе нормативы турында һәм Россия Федерациясе субъектлары буенча 2024 елның I кварталына торак бинаның гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар бәясе күрсәткечләре турында» 888/пр номерлы боерыгына ярашлы рәвештә 2024 елның I кварталына Татарстан Республикасында торак бинаның гомуми мәйданының бер квадрат метры бәясе нормативы 133 129 сум күләмендә билгеләнгән.

Моны исәпкә алып законны гамәлгә ашыруга 2024 елда Татарстан Республикасы бюджетыннан 100 000 мең сум күләмендә акча бүлеп бирү турында карар кабул ителде.